ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**18 июль 2023 ел**
**№ 22**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ, «Хайваннарга җаваплы караш һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 №489-ФЗ федераль законнар, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Арча районы прокуратурасының 15.05.2023 № 02-06-2023/Прдп 213 күрсәтмәсен караганнан соң, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. милек иясенең файдалануында яки милкендә булган җир кишәрлекләре;

1.2. кеше күп җыелмый торган авыл җирлеге территориясе, бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артында аларның хуҗалары күзәтүе астында борынчак һәм бәйләвечтә:

- Курса-Почмак авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Үзәк урамыннан 250м ераклыкта;

-Югары Масра авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә, Киров урамыннан 50 м ераклыкта;

-Иске Му авылының көнчыгыш-төньяк өлешендә, Кооператив урамыннан 100м ераклыкта;

-Сикертән авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Мәктәп урамыннан 150м ераклыкта;

-Гөберчәк авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә, М.Мәһдиев урамыннан 100м ераклыкта;

-Мөрәле авылының көнчыгыш-төньяк өлешендә, Үзәк урамыннан 100м ераклыкта;

-Сеҗе авылының көнчыгыш-төньяк өлешендә, Вахитов урамыннан 200м ераклыкта;

-Ташкич авылының көнбатыш-көньяк өлешендә, Х.Такташ урамыннан 200м ераклыкта;

-Починок-Поник авылының көнбатыш-көньяк өлешендә, Ф.Бикбаев урамыннан 150м ераклыкта;

-Курса тимер юл разъездында төньяк-көнбатыш өлешендә,Урман урамыннан 50м ераклыкта;

-Яңа Чуриле авылының көнбатыш-төньяк өлешендә, Мәктәп урамыннан 50м ераклыкта.

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дип язылган такталар урнаштырырга.

2. Йорт хайваннарын йөртү гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклау шартларында башкарылырга тиеш.

2.1. Этне йөртү аның озынлыгы этнең үз-үзен тотышын контрольдә тотарга мөмкинлек бирә торган бәйләвеч (этне тотып торучы башка җайланма) кулланып башкарылырга тиеш (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган әлеге карарның 5 пункты нигезләмәләре куллана торган потенциаль куркыныч этләрне йөртүдән тыш).

3. Рөхсәт ителми:

3.1. Йорт хайваннарын балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар территориясендә, халык күпләп ял итү урыннарында, балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре, мәдәният, кибет объектларына якын территорияләрдә ирекле йөртү, хайваннар белән бергә йөрү өчен махсус объектлардан тыш.

3.2. 3.1 пунктның гамәлдә булуы сукырларга юл күрсәтүче этләргә кагылмый.

3.3. Этләрне йөрткән вакытта караучысыз калдыру;

3.4. Этләрне алкоголь, наркотик яки токсик исерек хәлдә булган, шулай ук яшьләре яки сәламәтлекләре аркасында этләрнең хәрәкәтләрен контрольдә тота алмаган һәм аларның агрессив тәртибен туктата алмаган затлар йөртү.

4. Йорт хайванын йөрткәндә, барлык очракларда да, хуҗа үзе белән экскрементлар җыю өчен кирәкле әйберләр алырга һәм шунда ук үзенең йорт хайваны артыннан, шул исәптән подъездлар, баскычлар, лифтлар, балалар мәйданчыклары, җәяүлеләр юллары, подваллар һәм торак йортлар һәм торак зоналарда гомуми файдаланудагы башка урыннарда экскрементларны җыештырырга тиеш.

5. Йөртү урынына карамастан, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган потенциаль куркыныч этләрне борынчаксыз һәм бәйләвечсез йөртү тыела, потенциаль куркыныч этне потенциаль куркыныч эт хуҗасына милек хокукында яки башка законлы нигездә караган киртәләнгән территориядә йөртүдән тыш. Әлеге территориягә кергәндә мондый этнең булуы турында кисәтү язуы булырга тиеш.

6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Курса-Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт; ТР, Арча районы, Сикертән авылы, Үзәк урамы, 14 йорт; ТР, Арча районы, Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25 йорт.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы : Хамидуллин Р.В.